# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Чәкән торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

**№ 2** **13 ноябрь 2025 ел.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Чәкән торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең Чәкән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 теркем инвалидлардан, 2 төркем инвалидлардан кендезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнарыннан тыш, 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салымны кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары, махсус җайланмалар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урам яктырткычларын алмаштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);

2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны кышын һәм җәен карап тоту, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, паркны карап тоту һәм аңа якын территорияне төзекләндерү, үләнне чаптыру, чүп җыю, үсентеләр сатып алу)

3) ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын тезекләндерү (агачларны кисү, куакларны кисү, рус зиратында чүп җыю).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан: Чәкән авылы, Базар ур, 2 мәгълүмат стендларында, урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахит авыл җирлеге Башлыгы Г.И. Әскәрова